**РЕШЕНИЕ**
КАЗАНСКОЙ
ГОРОДСКОЙ ДУМЫ

КАЗАН ШӘҺӘРЕ
ДУМАСЫ
**КАРАРЫ**

26.02.2026 г.Казань № 3-6

**Казан шәһәре Думасының**
**2025 елдагы эшчәнлеге турында**
**хисап хакында**

Казан шәһәре Думасының 2025 елдагы эшчәнлеге турында хисап Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә депутатларга карап тикшерүгә тәкъдим ителә һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы Татарстан Республикасы законы, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы белән билгеләнгән компетенция һәм вәкаләтләр нигезендә гамәлгә ашырылган депутатлар эшчәнлеген чагылдыра.

Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының Казан шәһәре Думасының Казан шәһәре халкы алдында хисап тотуы һәм алар контролендә булуы турындагы 24 статьясы нигезләмәләреннән чыгып, Казан шәһәре Думасы **карар кабул итте**:

1. Казан шәһәре Думасының 2025 елдагы эшчәнлеге турында хисапны расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Казан шәһәре Думасы депутатларына округларда Казан шәһәре Думасы эшчәнлеге турында сайлаучыларга мәгълүмат җиткерү эшен дәвам итүне йөкләргә.

**Шәһәр Мэры** **И.Р.Метшин**

Казан шәһәре Думасының
2026 елның 26 февралендәге
3-6 номерлы карарына
кушымта

**Казан шәһәре Думасының**
**2025 елдагы эшчәнлеге турында**
**хисап**

Казан шәһәре Думасының Казан шәһәре халкы алдында хисап тотуы һәм алар контролендә булуы турындагы Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы нигезләмәләренә таянып, депутатлар корпусы эшчәнлегендә дәвамлылыкны саклап, Шәһәр Думасы казанлыларга 2025 елдагы эшчәнлеге турында хисап бирә.

Шәһәр Думасында сәяси партияләрнең дүрт фракциясе формалашты: «ЕДИНАЯ РОССИЯ» (38 депутат), «СПРАВЕДЛИВАЯ РОССИЯ» (3 депутат), КПРФ (4 депутат), ЛДПР (2 депутат).

Казан шәһәре Думасы структурасында Президиум, җиде даими депутатлар комиссиясе, «Өмет – Надежда» хатын-кыз депутатлар төркеме, шулай ук район депутатлары төркемнәре булдырылды.

Шәһәр Думасы, үз вәкаләтләре чикләрендә һәм дәвамчанлык принцибын саклап, шәһәр халкы мәнфәгатьләрендә эзлекле һәм принципиаль эш алып бара.

2025 елның 14 сентябрендә, Бердәм тавыш бирү көнендә, Казан шәһәре территориясендә Татарстан Республикасы Башлыгын (Рәисен) һәм бишенче чакырылыш Казан шәһәре Думасы депутатларын сайлаулар узды.

Шәһәрдә 464 сайлау мәйданчыгы эшләде. Шәһәр Думасына депутатлар сайлауда 200 дән артык кандидат теркәлгән иде. Бишенче чакырылыш Казан шәһәре Думасына сайлаулар нәтиҗәләре буенча 50 депутат сайланды: 25 депутат – бердәм сайлау округы буенча, 25 депутат – бермандатлы округлар буенча.

2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы «Ачык хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль законның 25 статьясындагы 6 пункты нигезендә дүртенче чакырылыш депутатларының вәкаләтләре муниципаль берәмлекнең яңа чакырылыш вәкиллекле органының тулы хокуклы составтагы беренче утырышын уздырган көннән туктатылды.

Шәһәр Думасының төп эш формасы булып сессия тора. Узган чорда

9 сессия үткәрелде һәм шәһәрне үстерүгә һәм шәһәр хуҗалыгының барлык тармакларында эшне оештыруга юнәлдерелгән 155 карар кабул ителде.

Шәһәр Думасы Президиумы 2025 ел дәвамында Шәһәр Думасы сессияләрендә карап тикшерү өчен мәсьәләләр әзерләүне оештырды, даими комиссияләрнең һәм фракцияләрнең хисапларын тыңлады.

Барлык фракция депутатлары дәрәҗәләр арасындагы хезмәттәшлек турындагы килешүләрне гамәлгә ашыру кысаларында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм Россия Федерациясе Федераль Җыены Дәүләт Думасы депутатлары белән берлектә шәһәрне, аның инфраструктурасын үстерү һәм шәһәр проблемаларын хәл итүгә өстәмә акча җәлеп итү мәсьәләләрен хәл итүдә катнаштылар.

Шәһәр Думасы тарафыннан карап тикшерүгә кертелә торган барлык мәсьәләләр буенча даими комиссияләр утырышларында мәҗбүри рәвештә фикер алышулар үткәрелде, депутатлар округларда сайлаучылар белән алдан очрашты, мәсьәләләрне хәл итүгә экспертлар һәм тармак белгечләре җәлеп ителде.

Даими комиссияләр һәм Шәһәр Думасына карап тикшерү өчен кертелә торган мәсьәләләрне тирәнрәк өйрәнү максатыннан эшче төркемнәр төзелде, тикшерүләр һәм объектларга чыгулар оештырылды. Узган елда даими комиссияләр тарафыннан 91 утырыш уздырылды (2024 елда – 86), аларда 193 мәсьәлә карап тикшерелде (2024 елда – 181).

Шулай итеп, 2025 елда сессияләрдә һәм даими комиссия утырышларында карап тикшерү өчен мәсьәләләр әзерләгәндә, депутатларның шәһәр, коммуналь хуҗалык объектларына баруы оештырылды һәм шәһәр халкы, учреждение җитәкчеләре белән булган проблемалар турында фикер алышулар уздырылды.

Депутатлар түбәндәге юнәлешләр буенча эшләде.

## Социаль-икътисади үсеш, муниципаль милек белән идарә итү һәм аннан файдалану

Эшнең төп юнәлеше – Казан шәһәре Башкарма комитетының социаль-икътисади үсеш, муниципаль милек белән идарә итү, кече һәм урта эшмәкәрлеккә ярдәм итү, шәһәрнең туристлык потенциалын арттыру өлкәсендәге эшчәнлегендә катнашу һәм аны контрольдә тоту.

Казан шәһәрен социаль-икътисади яктан үстерү стратегиясен (алга таба – Стратегия) гамәлгә ашыру мәсьәләсе элеккечә төп мәсьәләләрнең берсе булып калды.

Казан шәһәре Думасы депутатлары Стратегияне гамәлгә ашыру һәм

халыкның тормыш сыйфатын характерлаучы максатчан ориентирларны үтәү буенча чаралар планын анализлау эшен системалы рәвештә башкардылар.

Шулай ук 2025 елда Казан шәһәре Думасы депутатлары 2030 елга кадәр (перспективада 2040 елга кадәр) Казанның тотрыклы үсеш стратегиясен кабул иттеләр. Стратегия биш төп юнәлешне үз эченә ала: ике бүлек – экологиягә, калганнары тормыш сыйфатын яхшыртуга, икътисади үсешкә һәм идарә итүгә багышланган. Документ экохәрәкәт һәм чүп-чарны эшкәртү, экологик туристик маршрутлар булдыру, шулай ук бизнес үсешенә ярдәм итәчәк.

Казан шәһәрендә кече һәм урта эшмәкәрлеккә ярдәм итү һәм аны үстерү мәсьәләсен карап тикшерү дәвам итте.

2025 елда Казанда 86 290 кече һәм урта эшмәкәрлек субъекты үз эшчәнлеген алып барды, шулардан: кече һәм микропредприятиеләр – 37 758, урта предприятиеләр – 298, шәхси эшмәкәрләр – 48 234.

Кече һәм урта эшмәкәрлек субъекты секторында эшләүчеләр саны – 429 меңнән артык кеше. 2025 елның сигез аенда кече предприятиеләрдәге әйләнеш 841,5 млрд сум тәшкил итте.

Казан шәһәренең кече бизнесы – эчке территориаль продуктның 42,5 проценты, шәһәрдәге барлык эшләүче халыкның өчтән бере һәм шәһәр бюджетына салым керемнәренең 41,5 проценты.

2025 елның сигез аенда кече предприятиеләр хезмәткәрләренең айлык уртача хезмәт хакы 48,7 мең сумга җитте, бу, 2024 елның шушы чорына караганда, 25,4 процентка күбрәк (2024 елның сигез аенда – 38,9 мең сум).

2025 елның 12 ае нәтиҗәләре буенча шәһәр казнасына кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларыннан кергән салым суммасы 13,4 млрд сумны тәшкил итте, бу 2024 ел дәрәҗәсеннән 14,1 процентка күбрәк.

Муниципаль заказ кысаларында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары өчен урнаштырылган конкурентлы сатып алуларның гомуми күләме 2025 елның 4 339,83 млн сум тәшкил итте, яисә гомуми муниципаль заказ күләменең 30,74 проценты (2024 елның – 3305,93 млн сум, яисә гомуми муниципаль заказ күләменең 27,71 проценты).

Федераль һәм республика ярдәм чаралары кысаларында 2025 елның 11 ае эчендә эшмәкәрләр 14,9 млрд сум күләмендә акча алды, шул исәптән федераль программалардан – 1 224 кече һәм урта эшмәкәрлек субъекты (гомуми суммасы 13,1 млрд сум), республика программаларыннан 316 кече һәм урта эшмәкәрлек субъекты (гомуми суммасы 1,8 млрд сум) файдаланды.

Муниципаль ярдәм чаралары җыелмасы эшләвен дәвам итә, аңа түбәндәгеләр керде:

- штрафларга мораторий (2025 елның штрафлар урынына 1554 кисәтү һәм 693 искәртү ясалды);

- кафелар каршында бушлай җәйге верандалар урнаштыру (2025 елда җәйге верандалар урнаштыруга 128 килешү төзелде).

Муниципаль биналарны ташламалы арендалау буенча «Аренда каникуллары» программасы кысаларында Казандагы эшмәкәрләргә һәм үзмәшгульләргә милек ярдәме күрсәтелде. Ташламалы аренда шартларында 5,8 мең кв.м гомуми мәйданга 38 килешү төзелде, 37 арендага алучы – кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары арендалана торган урынны сатып алу буенча өстенлекле хокуклардан файдаланды.

Үзмәшгульләр саны 33 252 кешегә артты һәм аларның саны 168 мең кешедән артып китте (163 165).

2025 елда шәһәрнең җәмәгать транспорты проблемалары депутатларның аерым контролендә булды.

Депутатлар транспорт өлкәсенә финанслау җитмәү сәбәпләрен карап тикшерделәр, шуңа бәйле рәвештә тулы күләмдә хәрәкәттәге состав сатып алу, транспорт инфраструктурасына капиталь ремонт ясау мөмкин түгел, кондукторлар һәм машина йөртүчеләр буенча кадрлар кытлыгы күзәтелә.

Казан шәһәренең шәһәр эчендәге пассажир транспорты маршрут челтәре дүрт транспорт төреннән тора һәм түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

- 54 автобус маршруты, аларда 608 берәмлек хәрәкәттәге состав һәм 13 берәмлекле 6 сезонлы маршрут кулланыла, гомуми озынлыгы – 1,04 мең км;

- 90 трамвайдан торган 9 трамвай маршруты, озынлыгы – 240,45 км;

- 139 троллейбустан торган 11 троллейбус маршруты, озынлыгы – 275,14 км;

- 15 электр поезды (51 вагон) составы хезмәт күрсәтә торган бер метрополитен линиясе, 11 станциядән тора, озынлыгы – 18,2 км.

2025 елда 223,4 млн пассажир йөртелде, бу 2024 ел күрсәткеченнән 1,3 процентка кимрәк булды. 2025 елда ташламалы категорияле гражданнарның транспортта йөрүләре саны – 72,9 млн, бу 2024 ел дәрәҗәсенә карата 1,6 процентка артык булды (2024 елда – транспортта йөрүләр саны 71,8 млн). Казан шәһәрендә ай саен уртача 114 меңнән артык ташламалы транспорт картасы тулыландырыла, алар буенча 6,0 млн тапкыр транспортта йөрелә.

Депутатлар инициативасы буенча сайлаучылар мөрәҗәгатьләрен карап тикшерү һәм урынга чыгып тикшерү рейдлары нәтиҗәсендә 2025 елда 3700 дән артык юл билгесе урнаштырылды һәм нормаларга туры китерелде, светофорлар белән идарә итә торган 109 шкаф буялды, светофор объектларының төзексезлеге

турында 1560 тан артык гариза буенча эш алып барылды, «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасы аша килгән 1745 гариза буенча эш башкарылды.

Казанда туризмны үстерү перспективаларына 2025 елда зур игътибар бирелде.

2025 елда Казан шәһәренә 5,1 млн турист килде, бу, 2024 елдагыга (4,5 млн) караганда, 13 процентка артык. Шәһәрнең кунакханә фондын төрле категориядәге 238 урнаштыру урыны тәшкил итә. Казан шәһәренең номерлар фондында 8786 номер, 17 750 урын санала.

Шәһәребездә туристларны җәлеп итә торган төп урыннар булып, гадәттәгечә, «Казан Кремле» музей-тыюлыгы, җәяүлеләр өчен Бауман урамы, Иске Татар бистәсе, Кремль яр буе, «Урам» экстрим-паркы, шулай ук шәһәрнең күпсанлы музейлары тора.

2025 елда Казан Кремлендә 4 471 706 кунак булды. Туристларның күпчелеге Мәскәүдән һәм Мәскәү өлкәсеннән, Башкортостан Республикасыннан һәм Марий-Эл Республикасыннан, Чуваш Республикасыннан һәм Удмуртия Республикасыннан, Самара, Ульяновск һәм Свердловск өлкәләреннән, Санкт-Петербургтан килгән.

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының Миграция мәсьәләләре идарәсе статистикасы буенча 2025 елда Казан шәһәренә 198 036 чит ил гражданины килде, бу, 2024 елга караганда, 25,2 процентка кимрәк.

2025 елгы навигация чорында Елга порты 496 371 кешегә хезмәт күрсәтте. Бу, 2024 елга караганда, 7,3 процентка күбрәк. 2025 елда Казан шәһәренең Габдулла Тукай исемендәге халыкара аэропорты 5 384 816 кешегә хезмәт күрсәтте, бу, 2024 елга караганда, 0,3 процентка артыграк.

2025 елда Казан шәһәрендәге урнаштыру чараларының уртача йөкләнеше 60 процентны тәшкил итте. Гадәттәгечә, иң югары күрсәткечләр җәйге чорга һәм бәйрәм көннәренә туры килә.  Кайбер даталарда кунакханәләрнең йөкләнеше 90 проценттан артып китте.

2025 ел дәвамында Казанны халыкара һәм төбәкара туристлык базарларында алга җибәрү буенча актив эш алып барылды. Казан Мэриясе Tourism Plus Shanghai 2025 (Кытай Халык Республикасы) күргәзмәсендә; чик буе туристлык маршрутларын үстерү перспективалары, шул исәптән бу юнәлештәге төп пунктларның берсе буларак Казанның потенциалын файдалану турында фикер алышулар уздырылган «Бөек чәй юлы: Россия-Монголия-Кытай» (Хух-Хото, Эчке Монголия) эшлекле киңәшмәсендә; CITIE-2025 Халыкара күргәзмәсендә (Гуанчжоу, Кытай Халык Республикасы) – Discover Russia берләштерелгән стендында катнашу Казанны һәм Татарстан Республикасын

туристлык индустриясе профессионалларының һәм Кытайдан килүче потенциаль туристларның киң аудиториясенә күрсәтергә мөмкинлек бирде; Исфаханда 15 нче Халыкара туризм һәм гамәли сәнгать күргәзмәсендә (Иран Ислам Республикасы) катнашты.

Ел дәвамында партнер-шәһәрләр белән туристлык продуктларын бергәләп үстерүгә һәм тәҗрибә уртаклашуга юнәлдерелгән яңа килешүләр төзелде.

2025 елның 9-13 апрелендә Казан шәһәренең депутатлар корпусы делегациясе Беларусь Республикасының башкаласына – Минск шәһәренә рәсми эшлекле сәфәр кылды. Әлеге сәфәр барышында ирешелгән килешүләр нәтиҗәләре буенча Казанда Минск көннәре уздырылды. Анда Минск шәһәре башкарма комитетының (Беларусь Республикасы) Спорт һәм туризм буенча баш идарәсе белән үзара аңлашу һәм хезмәттәшлек турында меморандум имзаланды. Реклама баннерларын үзара алмашып урнаштыру буенча кампания гамәлгә ашырылды.

2025 елда Казан Халыкара Russian Event Awards премиясенең «2025 елның вакыйгага бәйле туризмы өчен иң яхшы шәһәр» номинациясендә җиңү яулады.

Масштаблы «Төнге велофест» фестивале XII Бөтенроссия «Ел маршруты» премиясендә «Патриотик туризм өлкәсендә иң яхшы вакыйга» номинациясендә өченче урынны алды, шулай ук «Иң яхшы велосипед маршруты» номинациясендә «Киң күләмле велопроект өчен» махсус дипломы белән бүләкләнде.

XVIII Халыкара «Яшисе килә торган шәһәр» Бәйсез Дәүләтләр Берлеге һәм Евразия икътисади союзы шәһәрләренең шәһәр практикалары смотр-конкурсы нәтиҗәләре буенча Казан «Кунакчыллык йолдызлары» төбәкара һөнәри осталык фестивален үткәрү өчен, шулай ук шәһәрнең туристлык ресурсларын (go.kzn.ru порталы) комплекслы алга җибәрү өчен бүләкләргә лаек булды.

2025 елда депутатлар катнашында соңгы өч елда катнашучылар саны буенча дөньяда иң зур архитектур форум булган «Казаныш» үткәрелде. Халыкара архитектура-төзелеш форумында 45 меңнән артык кеше катнашты, тагын 17 мең кеше онлайн-трансляциягә кушылды. Дискуссияләрдә 23 илдән 400 дән артык спикер эшләде. IV «Казаныш» форумының эшлекле программасы тарихта иң масштаблы булды: БРИКС илләре буенча сигез тематик панель һәм БРИКС+ илләренең архитектура сәясәте, биоклиматик архитектура, кеше ихтыяҗларына йөз тоту, тарихи мохит редевелопменты һәм киләчәк шәһәрләрен булдыру темаларын үз эченә алган 115 тән артык сессия.

Шулай ук бишенче чакырылыш Казан шәһәре Думасының IV сессиясендә депутатлар 2026-2028 елларга муниципаль милекне хосусыйлаштыруның

фаразлау планы (программасы) турында карар кабул иттеләр.

Муниципаль милек белән идарә итүнең нәтиҗәлелеген арттыру һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетының керем өлешен тулыландыру максатыннан 2026-2028 елларда Казан шәһәренең муниципаль берәмлеге устав капиталында өлеше булган ике акционерлык җәмгыятенең акцияләрен сату, гомуми мәйданы 18 257,99 кв.м булган 103 муниципаль милек объектын хосусыйлаштыру планлаштырыла.

## Бюджет һәм салым сәясәте

Казан шәһәре бюджетын формалаштыру, кабул итү һәм аның үтәлешен контрольдә тоту мәсьәләләре депутатларның игътибар үзәгендә булды. 2025 ел дәвамында Казан шәһәре Думасы депутатлары тарафыннан шәһәр бюджетына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында алты карар кабул ителде.

2025 ел бюджеты, алдагы еллардагы кебек үк, һәрвакыттагыча социаль юнәлешкә ия иде: акчаларның 74,8 проценты социаль-мәдәни өлкәне үстерүгә юнәлдерелде.

Социаль яктан әһәмиятле чыгымнар тулы күләмдә финансланды: Казан шәһәренең муниципаль казна, бюджет һәм автоном учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәт хакы, муниципаль учреждениеләрнең коммуналь түләүләре, бюджет һәм автоном учреждениеләрнең муниципаль биремнәрен үтәүгә субсидияләр, белем бирү учреждениеләре укучыларының туклану чыгымнары, балалар мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә йөргән өчен ата-аналар түләвенең бер өлешенә компенсация түләүләре, баланы опекун гаиләсендә һәм тәрбиягә алган гаиләдә тәрбияләгән өчен пособиеләр, балаларны гаиләләргә тәрбиягә алган ата-аналарга өстәмә түләүләр, педагогларга сыйныф җитәкчелеге өчен өстәмә түләүләр, җәмәгать транспорты хезмәтләреннән һәм башка хезмәтләрдән тигез файдалануны тәэмин итү өчен гражданнарның аерым категорияләренә бирелә торган ташламалар.

«Мәгариф» бүлеге буенча бюджет чыгымнары күләме – 40 052,9 млн сум, шул исәптән тармак муниципаль программаларын үтәү кысаларында террорчылыкка каршы чаралар уздыруга, белем бирү учреждениеләренең матди-техник базасын ныгытуга, шулай ук күзәтчелек органнарының күрсәтмәләрен үтәүгә 2025 елда 1 072,7 млн сум бүленде, каникуллар вакытында балаларны сәламәтләндерү муниципаль лагерьлары территориясендә җәмәгать тәртибен саклау чыгымнарын да кертеп, Казан шәһәрендә балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыруны финанслауга 468,5 млн сум җибәрелде, ә яшьләр сәясәте

өлкәсендә бюджет чыгымнары 647,8 млн сум тәшкил итте.

«Мәдәният» бүлеген финанслауга 2 254,4 млн сум акча тотылды. Бүлеп бирелгән акчалар мәдәният сарайлары һәм йортлары, китапханәләр челтәре, шәһәр музейлары һәм башка мәдәният учреждениеләре тарафыннан хезмәтләр күрсәтүгә, шулай ук мәдәният өлкәсендә шәһәркүләм чаралар үткәрүгә юнәлдерелде.

2025 елда «Физик культура һәм спорт» бүлеге буенча бюджет чыгымнары 3 077,4 млн сум тәшкил итте. Алар шәһәрдәге спорт мәктәпләрен, спорт корылмаларын карап тотуга, шулай ук массакүләм спорт чаралары уздыруга тотылды.

«Сәламәтлек саклау» бүлеге чыгымнары 64,0 млн сум күләмендә эпидемиягә каршы чаралар уздыруга юнәлдерелде.

Гомумдәүләт мәсьәләләрен гамәлгә ашыруга тотылган бюджет чыгымнары 7 993,7 млн сум тәшкил итте.

«Илкүләм иминлек һәм хокук саклау эшчәнлеге» бүлеге буенча чыгымнар күләме – 495,5 млн сум. Алар бердәм дежур-диспетчерлык хезмәте, хокук тәртибен саклау буенча терәк пунктлар эшчәнлеген тәэмин итүгә, шулай ук гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәләрен бетерүгә, пляжларны әзерләүгә һәм карап тотуга тотылды.

«Илкүләм икътисад» бүлеге буенча бюджет акчалары 5 154,5 млн сум күләмендә үзләштерелде, шуларның 4 284,5 млн сумы – урам-юл челтәрен карап тотуга, 735,4 млн сумы – транспорт өлкәсендәге чыгымнарга, 67,9 млн сумы илкүләм икътисад өлкәсендәге башка мәсьәләләрне финанслауга юнәлдерелде.

«Торак-коммуналь хуҗалык» бүлеге буенча чыгымнарны финанслауга 2 296,4 млн сум акча бүлеп бирелде, аңа торак фондына капиталь ремонт ясау, гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү, төзекләндерү объектларын агымдагы карап тоту һәм ремонтлау, шәһәрне чәчәкләр белән бизәү өчен тотылган чыгымнар керә.

«Әйләнә-тирә мохитне саклау» бүлеге буенча 116,3 млн сум күләмендә чыгымнар чистарту корылмаларын карап тотуга, табигатьне саклау буенча чаралар үткәрүгә юнәлдерелде.

2025 елда муниципаль бурыч буенча хезмәт күрсәтү өчен тотылган бюджет чыгымнары 27,0 млн сум тәшкил итте. Казан шәһәренең муниципаль бурычы белән идарә итүдә нәтиҗәле сәясәт алып бару расланган планнан 369,1 млн сум күләмендә экономия ясарга мөмкинлек бирде.

Депутатларның бюджет процессында актив катнашуы нәтиҗәсендә:

- шәһәр бюджетының төп параметрларының баланслылыгын һәм финанс

тотрыклылыгын саклап калуга ирешелде;

- кабул ителгән бюджет йөкләмәләре тулы күләмдә башкарылды;

- салым һәм салым булмаган керемнәр буенча план күрсәткечләре 7,9 процентка арттырып үтәлде, бу 2025 елда биналарны карап тотуга, агымдагы һәм капиталь ремонтлауга, муниципаль учреждениеләрне матди-техник яктан җиһазлауга, шәһәр территорияләрен төзекләндерүгә, шәһәр күләмендә чаралар оештыруга һәм үткәрүгә, проектларны гамәлгә ашыруга өстәмә акча тотарга мөмкинлек бирде.

## Шәһәр төзелеше һәм торак-коммуналь хуҗалык

Хисап елында депутатлар шәһәр территориясен төзекләндерү, Казан шәһәр округының Генераль планын, Шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативларын, Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен, Шәһәрне төзекләндерү кагыйдәләрен гамәлгә ашыру, шулай ук күрсәтелә торган торак-коммуналь хезмәтләрнең сыйфатын күтәрү мәсьәләләренә аерым игътибар бирделәр.

Казан шәһәре Думасы тарафыннан Казан шәһәре Башкарма комитетының Архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсе, шулай ук «Татарстан Республикасының пространстволы планлаштыру институты» дәүләт бюджет учреждениесе белән берлектә Казан агломерациясен социаль-икътисади һәм пространство ягыннан үстерүнең комплекслы схемасын гамәлгә ашыру буенча чаралар планын карап тикшерү һәм аңа төзәтмәләр кертү эше башкарылды.

Шәһәр төзелеше өлкәсендә хокукый җайга салуны камилләштерү, Казан шәһәре халкы өчен уңайлы тормыш шартлары булдыру максатыннан депутатлар тарафыннан Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә 28 тапкыр үзгәрешләр хупланды һәм кертелде.

Казан шәһәре Думасы катнашында зур күләмдәге финанс чаралары Казан шәһәренең Генераль планында каралган инфраструктура белән бәйле эре юл объектларын төзүгә һәм реконструкцияләүгә җибәрелде.

Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт торак фонды инвестор булып торган Социаль ипотека программасын гамәлгә ашыру дәвам итте. Ел нәтиҗәләренә караганда, объектлар буенча башкарылган эшләрнең гомуми күләме 8,1 млрд сум тәшкил итте.

2025 елда түбәндәге социаль инфраструктура объектларында эшләр тәмамланды:

- Кремль урамындагы 1 һәм 7/1 йортларда урнашкан «Шәһәр Думасы

биналары комплексы» төбәк әһәмиятендәге һәм федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объекты. Хәзерге вакытта гомуми мәйданы 2 754,3 кв.м булган объект файдалануга тапшырылды;

- Миславский урамы, 4 йорт адресы буенча урнашкан «Харитонов типографиясе, 1896 ел» төбәк әһәмиятендәге мәдәни мирас объекты;

- Воровский урамында коммуналь хезмәтләр өлкәсендә хезмәт күрсәтү базасы (1 нче этап, 2 нче этап) төзелеше. Хәзерге вакытта гомуми мәйданы 7 578,20 кв.м булган объект файдалануга тапшырылды;

- Даурия урамында механикалаштыру базасы һәм теплица хуҗалыгы төзелеше. Хәзерге вакытта гомуми мәйданы 12 024,3 кв.м булган объект файдалануга тапшырылды;

- Профсоюз урамы, 25/15 йорт адресы буенча урнашкан бинаның фасадын капиталь ремонтлау;

- Дементьев урамы, 2б йорт адресы буенча урнашкан административ бинаның бүлмәләрен капиталь ремонтлау;

-«“Лидер” яшүсмерләр клубы» объектында тышкы инженерлык челтәрләрен төзү;

- Татарстан һәм Г.Тукай урамнары киселешендә торак булмаган бинаны (даруханәне) сүтү.

Үзәкләштерелгән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең Казан шәһәре Киров һәм Мәскәү районнары мөхтәсибәте карамагындагы Җирле мөселман дини оешмасы – «Сөләйман» мәчете мәхәлләсе белән килешү кысаларында «Серов урамы, 4а йорт адресы буенча “Ярдәм” инклюзия үзәге» бинасы» объекты төзелә.

2025 ел дәвамында торак-коммуналь хуҗалык өлкәсе депутатлар өчен мөһим юнәлеш булды.

Казан шәһәре торак фондының гомуми мәйданы – 52,3 млн кв.м: 5915 күпфатирлы йорт (43,8 млн кв.м), 115 тулай торак (0,5 млн кв.м), 61 417 шәхси торак йорт (8,03 млн кв.м).

Казан шәһәрендә күпфатирлы йортлар белән идарә итә: 137 идарәче компания – идарәсендә 5086 күпфатирлы йорт (йортларның 84,2 проценты); 740 торак милекчеләре ширкәте һәм торак-төзелеш кооперативы – идарәсендә 858 күпфатирлы йорт (йортларның 14,3 проценты). 86 күпфатирлы йорт (йортларның 1,5 проценты) белән турыдан-туры милекчеләр идарә итә.

Депутатларның күпфатирлы йортларны агымдагы ремонтлау программасын гамәлгә ашыруны даими контрольдә тотуы нәтиҗәсендә

2025 елда 834 йортта 913,7 млн сумлык ремонт ясалды, шул исәптән ремонтланды:

- температура-дымлылык режимын нормальләштерү буенча барлык кирәкле чараларны үтәп, 39 түбә;
- 69 йортта төтен юллары һәм вентиляция каналлары;
- 78 йортның фасады;
- 39 йортта үзәк җылыту системасы;
- 43 йортта кайнар су белән тәэмин итү системасы;
- 58 йортта салкын су белән тәэмин итү системасы;
- 51 йортта канализация системасы;
- 15 йортта һава торышы буенча көйләү узеллары;
- 99 йортта электромонтаж эшләре башкарылды.

2025 елда күпфатирлы йортларны капиталь ремонтлау программасы буенча 224 йортка 4,0 млрд сумлык ремонт ясалды, бу әлеге йортларда яшәүче 67 меңнән артык кешенең яшәү шартларын яхшыртырга мөмкинлек бирде.

Төп эшләр – инженерлык коммуникацияләрен алмаштыру, фасадлар һәм түбәләрне ремонтлау, шулай ук лифт җиһазларын алмаштыру.

55 түбә алмаштырылды; 46 йортта җылылык системасы ремонтланды; 47 йортның фасады ремонтланды, шуларның 22 сендә җылыту эшләре башкарылды; 45 йортта – салкын су белән тәэмин итү инженерлык системалары, 19 йортта – кайнар су белән тәэмин итү системалары, 46 йортта су чыгару системалары алмаштырылды; 2 йортта янгыннан саклау системасы ремонтланды, 10 йортта 12 һава торышы буенча көйләү узелы урнаштырылды.

Лифт җиһазларын алмаштыру тәмамланды: 141 йортта 457 лифт алмаштырылды.

2018 елдан башлап депутатлар катнашында Казан шәһәрендә калдыкларны җыюның дуаль системасы барлыкка килде һәм үсә бара. Контейнер мәйданчыкларында катнаш каты коммуналь калдыклар өчен евроконтейнерлардан кала, органик булмаган калдыкларны биш төрле фракциягә: пыяла, пластик, кәгазь, металл һәм тетрапакка аерып җыю өчен билгеләнгән махсус сары челтәрле контейнерлар урнаштырылды.

Хәзерге вакытта Казан шәһәрендә каты коммуналь калдыклар җыю өчен 2000 мәйданчыкта 2463 махсус сары челтәрле контейнерлар урнаштырылды.

2025 елда Казан шәһәрендә 924 махсус сары челтәрле контейнер урнаштырылды/алмаштырылды.

635 контейнер ремонтланды һәм алмаштырылды. 892 яңа контейнер куелды. Шәхси торак төзелеше территориясендә 36 бункер 241 евроконтейнерга

алмаштырылды, каты коммуналь калдыклар җыю өчен 22 мәйданчык реконструкцияләнде.

Калдыкларны икенчел эшкәртү өчен махсус билгеләнгән мәйданчыкларда җыюны күздә тоткан «Җыю ноктасы» экологик проекты гамәлгә ашырылды. Беренче «Җыю ноктасы» 2023 елның ноябрендә Васильченко урамы, 6 йорт адресы буенча ачылган иде. Эшләү дәверендә төрле фракцияләрдән торган 124 тоннадан артык икенчел чимал җыеп алынды. Алар арасында иң күп очраганы – йомшак пластик, картон, ПЭТ һәм резина.

Икенче «Җыю ноктасы» кабул итү пункты 2025 елның апрелендә Родина урамы, 45 йортта ачылды. Биредә көн саен 35 тән артык фракция: пластик, металл, пыяла, макулатура, тетрапак, шулай ук пенопласт, пауч тартмалар, электроника, кием-салым, җиһаз, автомобиль покрышкалары һәм дару блистерлары яки пластик карталар кебек вак фракцияләр кабул ителә. Пунктка 16 меңнән артык кеше килде. Апрельдән алып 139 тоннадан артык икенчел чимал җыелды.

Халыктан икенчел чимал җыю буенча эшмәкәрләр проектлары да үсеш алды. Хәзерге вакытта икенчел чимал кабул итү буенча 19 пункт эшли. Әлеге кабул итү пунктларында макулатура, алюминий банкалар, картон, ПЭТ-шешәләр, металл ватыклары, металл калдыклары, эре көнкүреш техникасы (суыткычлар, кер юу машиналары һәм газ плитәләре), ә кайберләрендә, электрон җиһазларны, чыбыкларны һәм энергия җыю җайланмаларын да кертеп, ватык радиоэлектроника детальләрен, кием-салым, аяк киеме, китаплар, журналлар, савыт-саба, балалар уенчыклары, көнкүреш техникасы кебек икенчел чимал тапшырган өчен акча түлиләр.

Хәзерге вакытта булган «Җыю ноктасы» пунктларыннан тыш, Үзәк Мариуполь урамы, 49б адресы буенча Green City һәм Давыдов урамы, 75 адресы буенча «АртЭко» икенчел чималны сортларга аеру пунктлары ачылды. Тагын шундый 20 пунктны файдалануга тапшыру планлаштырыла.

Казан шәһәре территориясендә текстиль эшләнмәләр җыю проекты Россиянең «Ай Джей Интернешнл Групп» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте компаниясе тарафыннан 2024 елдан гамәлгә ашырыла. Компаниянең контейнер мәйданчыкларында урнаштырылган контейнерларына барлык төр текстиль әйберләр, шул исәптән кием-салым, аяк киеме, сумкалар, йомшак уенчыклар һәм теләсә нинди хәлдә булган өй текстиле кабул ителә. Проектны гамәлгә ашыруның ике елында 200 тоннага якын текстиль эшләнмәләр җыелды, Казан шәһәре территориясендә 226 контейнер урнаштырылды.

Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан хупланган инвестиция

проектын гамәлгә ашыру кысаларында, Казан шәһәре, Мамадыш Тракты урамы, 120Д адресы буенча төзелеш калдыкларын утильләштерү мәйданчыгы уңышлы эшли.

2024 ел ахырында файдалануга тапшырылган «Восточный» каты коммуналь калдыклар полигонында ел әйләнәсе эшләү куәте тәүлегенә 150 куб.м булган, тулысынча автоматлаштырылган фильтрат чистарту корылмалары файдаланыла. Бу корылмалар Россия җитештерүчесе «Яңа торба технологияләре» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан нигездә илебездә җитештерелгән комплектлаучы детальләр кулланып эшләнгән һәм җыелган.

Кулланыла торган технологиянең төп аермасы – биологик чистарту блогы булу (чистарту фильтратны туклану буларак куллана торган микроорганизмнар тарафыннан башкарыла).

Торак-коммуналь хуҗалык һәм су белән тәэмин итү өлкәсендә депутатлар тарафыннан җылыту сезонына әзерлекне бәяләү буенча даими контроль алып барыла.

Әлеге эш кысаларында 34,6 км дан артык җылыту һәм кайнар су белән тәэмин итү челтәрләре реконструкцияләнде. «Казэнерго» акционерлык җәмгыятенең өч котельныйсында котельный агрегатлары һәм искергән җиһазлар модернизацияләнде.

Казан ТЭЦ-1 дән алып «Горки» котельныйсына кадәр 5 номерлы магистраль җылылык үткәргеч төзү эше дәвам иттерелде. Объект Г.Кутуй, Даурия һәм Родина урамнары тирәсендәге яңа мәйданчыкларны тоташтырырга мөмкинлек бирәчәк. Шул ук вакытта 1 920 680 кв.м мәйданлы торак фондын, 133 000 кв.м мәйданлы коммерция мәйданнарын, 12 мәктәпне, 20 мәктәпкәчә белем бирү учреждениесен файдалануга тапшыру планлаштырыла.

## Мәгариф, мәдәният һәм милли мәсьәләләр

Мәгариф системасын үстерү – депутатлар корпусы эшчәнлегенең өстенлекле юнәлеше булып торды.

Депутатлар күтәргән һәм карап тикшергән иң мөһим мәсьәләләр:

- Казан шәһәре мәгариф учреждениеләренең иминлеге һәм террорчылыктан сакланган булуы;
- укучыларда гражданлык һәм патриотлык хисләре тәрбияләү;
- өч яшькә кадәрге балалар өчен мәктәпкәчә белем алу мөмкинлеген тәэмин итү;

- балаларны сыйфатлы туклану белән тәэмин итү.

Казанда барлыгы эшләп килә: 344 балалар бакчасы, шуларның 303 е – муниципаль һәм 15 е – мәктәпкәчә бүлекләр; 206 мәктәп, аларның 174 е – муниципаль; 49 өстәмә белем бирү учреждениесе. Шәһәрдә 250 меңнән артык бала белем һәм тәрбия ала, шулардан 182 008 бала – мәктәпләрдә (муниципаль мәктәпләрдә – 171 135, дәүләт мәктәпләрендә – 6 695, федераль мәктәпләрдә – 1 177, шәхси мәктәпләрдә – 3 001) һәм 67 960 бала – балалар бакчаларында тәрбияләнүчеләр (66 163 – муниципаль бакчаларда). Өстәмә белем бирү учреждениеләренә 71 245 укучы йөри.

2025 елда «Яшьләр һәм балалар» милли проекты кысаларында Казан шәһәре Совет районының «Лето» торак комплексында 1 224 урынга исәпләнгән яңа 123 номерлы физика-математика лицее ачылды. «33 нче Хәрби шәһәрчек» торак комплексында 220 урынга исәпләнгән балалар бакчасы төзелеше тәмамлана.

2025 елда үсешләрендә аерым ихтыяҗлар булган балаларны сыйфатлы белем белән тәэмин итү буенча эш дәвам итте. Мәктәпкәчә учреждениеләрдә аутистик спектры бозылган, психик үсеше тоткарланган һәм төрле яктан үсешләре нык бозылган 110 бала өчен 13 махсуслаштырылган төркем ачылды. Балалар бакчаларына 1131 инвалид бала йөри.

Моннан тыш, Казан шәһәре Яңа Савин районының «Татар телендә белем бирүче 13 номерлы гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесендә махсуслаштырылган кабинетлар ремонтланды һәм җиһазлар сатып алынды.

Шәһәрдә төрле нозология булган (ишетү, күрү сәләте бозылу, сөйләме нык бозылган булу, терәк-хәрәкәт аппараты кимчелекләре булу, психик үсештә тоткарлык булу, интеллектуаль яктан кимчелекләр булу, аутистик спектрда тайпылышлар булу) балаларны укыту өчен шартлар тудырылган 54 база мәктәбе эшләп килә. Махсус һәм ресурс сыйныфлары эшли. Муниципаль мәктәпләрдә барлыгы сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән 1 784 бала һәм инвалидлык категориясе булган 1 257 бала белем ала.

Сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән балалар белән күп еллар дәвамында системалы һәм нәтиҗәле эшләгәнлектән, Казанның мәгариф учреждениеләре Россиядә иң яхшылардан санала. 2025 елда Казан шәһәре Идел буе районының «78 номерлы “Фарватер” лицее» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе Россиянең иң яхшы инклюзив мәктәбе дип танылды.

Ел дәвамында депутатлар тарафыннан мәгариф учреждениеләрендә профильле укыту һәм һөнәр алды сыйныфлары кирәклеге турындагы мәсьәлә даими каралды.

Казанның 163 мәктәбендә белем бирү стандарты белән каралган барлык профильләр гамәлгә ашырыла.

Профильле 10-11 нче сыйныфлардан тыш, Казан шәһәрендә төрле юнәлештәге һөнәр алды сыйныфлары челтәре үсеш ала.

Казан шәһәренең гомуми белем бирү оешмаларында психологик-педагогик, медицина, агротехнологик юнәлештәге сыйныфлар, «Инженерлык республикасы», «“Энергокласс” энергетика профилендәге инженерлык сыйныфы», «Цифрлы (IT) сыйныф», «Авиатөзелеш профилендәге инженерлык сыйныфлары», «СИБУР-сыйныф», «Архитектура сыйныфы», «Торак-коммуналь хуҗалык сыйныфы», «Казан милли тикшерену техник университетының инженерлык сыйныфы» проектлары, шулай ук гомуминженерлык юнәлешендәге сыйныфлар, шәһәр идарәсе сыйныфы, тимер юл сыйныфы, дипломатия сыйныфы, юстиция сыйныфлары, эшмәкәрлек, метрология, космос сыйныфлары эшли. Барлыгы – 21 юнәлеш.

Мәктәпләр укучыларны һөнәр үзенчәлекләре белән таныштыра, индустриаль партнерлар һәм һөнәри белем бирү учреждениеләре белән хезмәттәшлектә тармак серләрен аңлаталар.

Казан вертолет заводының уку-җитештерү үзәге, шәһәр территориясендә урнашкан көллиятләр белән хезмәттәшлектә мәктәп укучыларын эшче һөнәрләр белән таныштыру эше оештырылды. Лицензия алганнан соң, белем бирү учреждениеләре укучыларга һөнәрләрне турыдан-туры мәктәптә үзләштерүне оештыра.

«Казанның яңа педагогика сыйныфы» проекты кысаларында шәһәрнең 29 мәктәбендә 65 психологик-педагогик сыйныф эшләп килә, аларда 1 500 укучы югары белем бирүче мәгариф оешмалары педагоглары җитәкчелегендә, гадәти мәктәп предметларыннан тыш, педагогика һәм психология нигезләрен теориядә генә түгел, практикада да өйрәнә.

Шәһәр мәктәпләрендә укучылар өчен Россия Федерациясе халык артисты Денис Мацуевның «Новые имена» бөтенроссия проекты гамәлгә ашырыла. 2025 елда 4 укучы әлеге бәйгедә катнашты: Кайгородов Климентий, Баһавиев Камил, Шакирова Зәлинә. 16 номерлы балалар сәнгать мәктәбендә укучы Чапаева Софья стипендиат статусына ия булды.

Моннан тыш, балалар музыка һәм рәсем сәнгате мәктәпләренең, шулай ук балалар сәнгать мәктәпләренең талантлы 53 укучысы Казан шәһәре Мэры

стипендияләре бәйгесендә катнашты. 16 иң сәләтле бала Казан шәһәре Мэры стипендиясенә ия булды.

Шулай ук балалар сәнгать мәктәпләренең һәм Александр Сладковский җитәкчелегендәге Татарстан Республикасы Дәүләт симфоник оркестрының «Оркестрның тылсымлы кыллары» һәм «Балалар – балаларга» дигән уртак проектлары уңышлы гамәлгә ашырылып килә.

«Мәгариф» илкүләм проектының «Заманча мәктәп» федераль проекты кысаларында «98 номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе, «64 номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе һәм «174 номерлы гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе базасында «Кванториумнар» ачылды, аларга бүген Казанның 1500 дән артык укучысы йөри. Алар укучыларда заманча компетенцияләр һәм күнекмәләр, шул исәптән табигый-фәнни, математик, мәгълүмати белемлелекне үстерү, тәнкыйди һәм креатив фикерләүне формалаштыру максатыннан гомуми белем бирүнең эчтәлеген киңәйтүне тәэмин итәргә тиеш.

«Пилотсыз авиация системалары» илкүләм проектының «Илебезнең пилотсыз авиация системаларына ихтыяҗны үстерү» федераль проекты кысаларында Казанның алты мәктәбе базасында махсуслаштырылган сыйныфлар ачылды. Биналарга ремонт ясалды, җиһазлар урнаштырылды.

Әлеге махсуслаштырылган сыйныфларның төп максаты – мәгариф оешмаларында укучыларны һәм белем алучыларны пилотсыз авиация системаларын эшләү, җитештерү һәм эксплуатацияләү буенча белем алу мөмкинлекләренә күпләп җәлеп итү.

Табигатькә сакчыл караш тәрбияләү буенча гамәли күнекмәләрне үстерү, әйләнә-тирә мохитне системалы рәвештә өйрәнү һәм табигатьне саклау чараларында актив катнашу аша Казан шәһәре укучыларында экологик культура формалаштыру максатыннан 2025 елдан «Яшел эшләр шәһәре» проекты гамәлгә ашырыла, аның кысаларында шәһәрнең барлык белем бирү оешмаларында экология һәм табигатьне саклау акцияләре, экология бәйрәмнәре, уеннар, лекцияләр һәм иҗади конкурслар үткәрелә.

2025 елда 178 төп һәм урта белем бирү оешмасы, шулай ук 107 мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе базасында «Беренчеләр хәрәкәте»нең 232 беренчел бүлекчәсе ачылды, аларда барлыгы 85 945 бала шөгыльләнә. Ел саен 50 меңнән артык бала чараларда һәм конкурсларда катнаша.

1-4 нче сыйныф укучылары өчен «Орлята России» программасы тормышка ашырыла, 3500 дән артык беренче сыйныф укучысы бу хәрәкәткә кушылды һәм атрибутика алды.

Казан шәһәре Думасы депутатлары инициативасы буенча 2025 елда Казан шәһәренең гомуми белем бирү учреждениеләрендә патриотик тәрбия үзәкләре ачылды. Алар белем бирү оешмалары хезмәткәрләренә консультатив-методик ярдәм күрсәтәләр, шулай ук район һәм шәһәр дәрәҗәсендә патриотик чаралар үткәрәләр (139 номерлы гимназия, 67 номерлы мәктәп, 101 номерлы мәктәп, 60 номерлы мәктәп). 60 номерлы мәктәп территориясендә «Бердәмлек» хәрби-патриотик үзәген ачу планлаштырыла.

В 2025 елда депутатлар Казан шәһәре мәгариф учреждениеләрне террорчылыктан саклау өлкәсендә финанслау җитмәгән чараларны теркәүне дәвам иттеләр. Түбәндәге чаралар тормышка ашырылды:

- биш учреждение территориясенең коймалары ремонтланды;

- өч учреждение территориясенә керү/чыгу юлында контроль-үткәрү пункты урнаштырылды.

2025 елда мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрен ремонтлау буенча «Гаилә» илкүләм проекты старт алды. Казан шәһәрендә 2 балалар бакчасында: Совет районында Каштан урамы, 6 йорт адресы буенча 415 номерлы балалар бакчасында һәм Казан шәһәренең Яңа Савин районында Я.Гашек урамы, 9а йорт адресы буенча 302 номерлы балалар бакчасында эшләр (гомуми сумма – 130,1 млн сум) төгәлләнеп килә.

Федераль бюджетка өстәмә рәвештә Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Нургали улы Миңнеханов ярдәме белән республика бюджетыннан югарыда күрсәтелгән балалар бакчаларына комплекслы капиталь ремонт ясау өчен акча бүлеп бирелде.

«Яшьләр һәм балалар» милли проекты буенча 2025 елда Ю.Фучик урамы, 147 йорт адресы буенча урнашкан 125 номерлы гимназиядә ремонт эшләре, Россия Федерациясе Герое майор С.А.Ашихмин исемендәге 130 номерлы мәктәп бинасында ремонт эшләренең икенче этабы башкарылды. Инженерлык челтәрләрен алмаштыру, кабинетлар һәм ял зоналарында бизәү эшләре, фасадны ремонтлау эшләре тәмамланды.

Патриотик тәрбия практикасын өйрәнү кысаларында Казан шәһәре Думасы депутатлары «Патриот» республика спорт-патриотик үзәгендә булдылар.

«Патриот» үзәге яшьләр арасында физик әзерлек һәм патриотизмны үстерүгә юнәлдерелгән күптөрле чараларны гамәлгә ашыра. Аның базасында

өлкән сыйныф укучылары өчен 5 көнлек хәрби-кыр җыеннары, хәрби-гамәли спорт төрләре буенча республика спартакиадалары, югары уку йортлары студентлары арасында спартакиадалар, шулай ук тормыш иминлеге нигезләре укытучылары һәм патриотик юнәлештәге яшүсмерләр клублары җитәкчеләре катнашында методик җыеннар үткәрелә.

Депутатлар югары сыйныф укучыларының яшәү шартларын өйрәнделәр, музейда, электрон тирда булдылар һәм программада катнашучылар белән аралаштылар. «Авангард» хәрби-укыту җыеннары аеруча кызыксыну уятты, чөнки алар барышында Казан мәктәпләренең, лицейларның һәм гимназияләренең 10 нчы сыйныф укучылары тактика һәм стратегия өйрәнделәр.

Шулай ук учреждение базасында ял көннәрендә тактик медицина буенча курслар уза, аларда теләге булган һәр кеше бушлай катнаша ала.

Визит нәтиҗәсендә депутатлар яшьләр өчен патриотик һәм спорт программаларын алга таба үстерүгә ярдәм итү кирәклеге турында карар кабул иттеләр, чөнки ул шәһәрдәге яшьләр сәясәтенең төп юнәлеше булып тора.

Мәдәният өлкәсендә Казан шәһәре Думасы депутатлары ярдәме белән Казан беренче тапкыр популяр музыканы яшь башкаручыларының «Новая волна» халыкара конкурсын һәм ачык һавада VK Fest музыкаль-күңел ачу фестивален кабул итте. Шулай ук шәһәрдә «Алтын мөнбәр» Казан халыкара кинофестивале, «Игелекле дулкын» бөтенроссия балалар иҗаты мәдәни-хәйрия фестивале һәм башкалар узды.

2025 елда Казан шәһәрендә төрле оешмаларга караган 400 дән артык мәдәният учреждениесе һәм оешмасы эшчәнлек алып барды, 107 объект җирле үзидарә органнары карамагында тора.

Казан шәһәрендә яшәүчеләргә Үзәкләштерелгән китапханә системасы тарафыннан китапханә хезмәте күрсәтелә. Ул Үзәк китапханәне, Үзәк балалар китапханәсен, 47 филиалны үз эченә ала.

Китап укучылар саны – 198 079 кеше. Халыкны китапханә хезмәте белән тәэмин итү 17 процентны тәшкил итә. Китап фондында 2 555 921 нөсхә исәпләнә. Бер шәһәр кешесенә – 3 китап, бер укучыга 13 китап туры килә. Бирелгән китаплар саны – 4 591 237 данә.

Китапханәләрнең китап фондларын туплау өчен шәһәр тарафыннан тотылган акчаның гомуми күләме – 7 485,96 мең сум. 49 китапханәнең барысы да компьютерлар белән җиһазландырылган һәм Интернеттан файдалану мөмкинлеге белән тәэмин ителгән, 40 китапханәдә Wi-Fi нокталары урнаштырылган.

Шәһәр халкына иҗади мөмкинлекләрен гамәлгә ашырырга 16 муниципаль мәдәният йорты, шулай ук 3 мәдәния-ял учреждениесе (Рок мәктәбе, «Оперение» иҗади үсеш студиясе, «Апуш» балалар татар театр студиясе) ярдәм итә.

2025 елда Казан шәһәрендә халыкның төрле төркемнәренең социаль-мәдәни инициативаларына һәм һәвәскәрләр иҗатына ярдәм итү максатыннан 808 клуб берләшмәсе үз эшчәнлеген башкарды, аларда 15 759 кеше катнашты. Әлеге берләшмәләрнең гомуми саныннан 549 ы үзешчән халык иҗаты берләшмәләре булып тора, шул исәптән 365 е – 14 яшькә кадәрге балалар өчен, аларга 6 633 кеше җәлеп ителде.

2025 елда Казан шәһәренең мәдәни-ял учреждениеләре тарафыннан 7 304 чара үткәрелде, шуларның 2 922 се (41%) – 14 яшькә кадәрге балалар өчен.

2025 елда Казан шәһәре Думасы депутаты инициативасы белән оештырылган, муниципаль мәдәни-ял учреждениесе статусындагы «Апуш» балалар татар театр студиясе үз эшчәнлеген дәвам итте.

10 августтан 24 августка кадәр Татарстанның Әтнә районында беренче тапкыр лагерь форматында Туфан Миңнуллин исемендәге «Күзлек» балалар театр лабораториясе узды. Ул драматургның 90 еллыгына багышланган һәм Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе ярдәмендә «Апуш» студиясе тарафыннан оештырылган иде.

Казан шәһәренең музей мирасы фонды бик бай. Музей комплексы составына Константин Васильевның картиналар галереясы, Бакый Урманче музее, Әмир Мәҗитов музее, Илдар Зариповның галерея-студиясе, «Хәтер китабы» мемориалы һәм В.П.Аксеновның музей-йорты, шулай ук Казан шәһәренең рус фольклоры үзәге керә.

Музей фондларында төп фондның 36 440 берәмлеге һәм фәнни-ярдәмче фондның 18 361 берәмлеге исәпләнә. Россия Федерациясе Музей фондының дәүләт каталогына 36 440 предмет кертелгән. 2025 елда 18 яңа экспонат сатып алынды. Экспозициянең гомуми мәйданы –780 кв.м, фонд саклагыч 284 кв.м мәйданны били. 2025 елда музейга 110 859 кеше килгән.

Ватанны саклаучылар елына һәм Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 80 еллыгына, Казанның 1020 еллыгына багышланган чаралар 2025 елның мөһим вакыйгалары булды. Ватанны саклаучылар елы һәм Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 80 еллыгын бәйрәм итү кысаларында «Мәңгелек хәтер уты» (Казан Ратушасында), «Сугыш көйдергән шигырь юллары», «Катюша» (Илдар Зарипов галерея-студиясендә), «Буыннар истәлеге» («Хәтер Китабы» мемориалында)

күргәзмәләре ачылды, алар 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышы тарихына караган уникаль экспонатлар тәкъдим итте.

Казанның 1020 еллыгына Казан Ратушасында «Гүзәл урын... дөньяда бу Казан шәһәре» һәм Физик культура, туризм һәм спорт университетында «Меңьеллык Казан» күргәзмәләре, Әмир Мәҗитов музеенда «Меңьеллык мирасы. Гасырлар чигендә рәсем сәнгате», Константин Васильев картиналар галереясында «Саклаучылар» һәм «Татарстанның зәркән сәнгате» күргәзмәләре ачылды.

Хәтерне мәңгеләштерү, Ватанны саклаучылар елы һәм Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 80 еллыгын бәйрәм итү кысаларында Казанда мемориаль такталар һәм һәйкәлләр ачылды.

Казан шәһәренең Җиңү паркында Сухов Иван Степановичка (19.09.1907 – 11.10.1976), Тихонов Павел Ивановичка (12.07.1908 – 28.09.1946), Ульянов Иван Михайловичка (22.01.1914 – 15.02.1986) элегрәк куелмаган истәлек такталары урнаштырылды. 2025 елның 8 маенда Яңа Савин районының «Яшьләр» скверында фронтовик шагыйрь Фатих Кәримгә һәйкәл, Россия Герое Д.Р.Гыйлемханов исемендәге 42 номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе территориясендә (Комиссар Габишев урамы, 27А йорт) Россия Герое Дамир Гыйлемхановка бюст ачылды. 2025 елның 9 маенда Казанның Җиңү паркында тантаналы рәвештә истәлекле таш куелган мемориаль зона ачылды, аның урынында киләчәктә махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәйкәл куелачак. 2025 елның 28 августында Казанда, 188 номерлы күппрофильле лицей янында Бөек Ватан сугышында катнашкан Мәхмүт Гәрәевнең бюстын ачу тантанасы узды.

Шулай ук Туфан Абдулла улы Миңнуллинга, Кияметдин Алимбәк улы Абрамовка, Георгий Константинович Мосоловка, 1941 – 1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында катнашкан Татарстан Республикасы эчке эшләр органнары ветераннары Б.А.Ботовка, Ф.И.Горшковка, В.П.Шихобаловка мемориаль такталар урнаштырылды.

Депутатлар инициативасы белән Казанда «Патриотлар шәһәре»конкурсы үткәрелде. Конкурста катнашу өчен мәктәп укучылары «Яшь патриотлар», «Үзебезнекеләр өчен» һәм «Буыннар хәтере» номинацияләренең берсендә ике минутка кадәр дәвам иткән видеороликлар тәкъдим иттеләр. Балалар Бөек Ватан сугышы ветераннарына һәм махсус хәрби операциядә катнашучыларга ярдәм итүдә үзләренең инициативалары, шулай ук тарихи хәтерне саклау турында сөйләделәр.

Иҗади ярыш өч яшь категориясендә үткәрелде: 1 – 4 сыйныфлар, 5 – 8 сыйныфлар һәм 9 – 11 сыйныфлар. Чарада Казанның 116 белем бирү учреждениесеннән 150 укучы катнашты.

Конкурс нәтиҗәләре буенча 37 кеше бүләкләнде, шуларның 26 сы җиңүче булды, ә 11 укучы креатив якын килү, эмоциональ чыгыш һәм башка казанышлар өчен махсус бүләкләргә лаек булды.

## Яшьләр сәясәте, физик культура һәм спорт үсеше

Түбәндәге сораулар аеруча әһәмиятле булды:

- яшьләргә патриотик тәрбия бирү;
- балалар һәм яшьләрнең җәйге сәламәтләндерү ялын оештыру;
- Казан шәһәренең өченче чакырылыш яшьләр парламенты эшчәнлеге.

2025 елда Казан шәһәренең «“Яшүсмер” яшәү урыны буенча яшьләр (яшүсмерләр) клублары берләшмәсе» яшьләр сәясәте муниципаль бюджет учреждениесенең Левченко торак массивында гомуми суммасы 13,31 млн сумлык, «Компас» – гомуми суммасы 14,28 млн сумлык ике яшьләр (яшүсмерләр) клубы ремонтланды, «Лидер» клубында 179,96 млн сумлык ремонт эшләре дәвам итә.

69 объектны үз эченә алган «Яшүсмер» муниципаль бюджет учреждениесендә 2025 елда 560 түгәрәк һәм секциядә, иҗат һәм спорт берләшмәләрендә 20 меңнән артык балалар, яшүсмерләр һәм яшьләр, шулай ук 60 түгәрәк һәм секциядә сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле 144 бала шөгыльләнде.

2025 елда шәһәрдә яшьләр өчен 50 меңнән артык кешене колачлаган 30 дан артык чара үткәрелде.

Казан шәһәрендә Балигъ булмаганнар эшләре буенча бүлекчәләрдә төрле төрдәге исәптә торучы балигъ булмаганнарны яшүсмерләр клубларына җәлеп итү системасы формалаштырылды.

Төрле төрдәге исәптә торучы балигъ булмаганнар өчен 295 тәрбияләнүчене колачлаган 147 махсус чара үткәрелде. Төрле төрдәге исәптә торучы 65 тәрбияләнүче «Яшүсмер» муниципаль бюджет учреждениесенең түгәрәкләренә/секцияләренә даими рәвештә йөриләр.

Казан шәһәре Думасы депутатлары җәмәгать тәрбиячеләре сыйфатында эшкә җәлеп ителделәр.

2025 елда барлыгы 4 204 кеше катнашында 219 патриотик чара: иҗади һәм гамәли мастер-класслар, патриотик акцияләр, спорт-ял итү программалары,

конкурслар һәм күргәзмәләр, шулай ук гражданлык позициясен формалаштыруга, ил тарихы белән горурлануга һәм Ватанны саклаучыларның батырлыгына хөрмәт тәрбияләүгә юнәлдерелгән очрашулар һәм тематик дәресләр үткәрелде.

Казанның Киров районында «Яшүсмер» муниципаль бюджет учреждениесенең «Олимпиец» яшьләр яшүсмерләр клубы базасында сугышчан дан музее ачылды. Экспозиция нигезендә – «Обозник» гуманитар ярдәм төркеме активистлары махсус хәрби операция зонасыннан алып кайткан предметлар, шулай ук хәрбиләрнең гаилә архивларыннан алынган материаллар. Сугышчан дан музеенда барлыгы 270 кеше булды.

Казан шәһәрендә физик культураны һәм спортны массакүләм үстерү, шәһәр кешеләрен физик культура һәм спорт белән системалы шөгыльләнүгә тарту өчен шартлар тудыру 2025 елда Казан шәһәре Думасы депутатларының төп бурычларыннан берсе булып торды.

2025 ел ахырына Казанда физкультура һәм спорт белән даими шөгыльләнүчеләр саны 800 000 кешене тәшкил итте.

Казан шәһәрендә 19 муниципаль спорт учреждениесе эшләп килә, аларда 18 765 кеше 48 спорт төре белән шөгыльләнә.

Казан шәһәренең спорт мәктәпләрендә 642 тренер (540 ы – штатта, 102 се – икенче эш урыны буларак) эшли.

Казан шәһәренең муниципаль спорт мәктәпләрендә спортның иң массакүләм төрләре булып футбол, җиңел атлетика, нәфис гимнастика, хоккей, йөзү санала.

Муниципаль спорт мәктәпләрендә шөгыльләнүче 1 906 спортчы Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясе җыелма командалары составына керә, шулардан:

- 1 781 кеше Татарстан Республикасы җыелма командаларында;
- 125 кеше – Россия Федерациясе җыелма командаларында вәкил булып тора.

Гадәттәгечә, җәйге сәламәтләндерү кампаниясе чорында яшь спортчылар балалар лагерьларында ял итте. Әйтик, «Тасма» лагеренда 2025 елда бер сменаның дәвамлылыгы 18 көнне тәшкил итте, 1 160 кешегә барлыгы 4 смена (сменага 290 бала) оештырылды.

«Яшь гвардия» лагеренда бер сменаның дәвамлылыгы шулай ук 18 көнне тәшкил итте, барлыгы 4 смена оештырылды, аларда 1 840 кеше (сменага 280 бала) ял итте. Шулай ук язгы, көзге һәм кышкы чорларда 300 кешене колачлаган 7 шәр көнлек берәр смена үткәрелде (һәр сменада 100 бала).

Казан шәһәрендә барлыгы спортның 63 төре буенча 532 массакүләм спорт чарасы, шул исәптән 234 чемпионат һәм беренчелек, 53 кубок, 104 турнир һәм 84 массакүләм спорт чарасы, спартакиадалар кысаларында 57 чара үткәрелде. Аларда барлыгы 150 меңнән артык кеше катнашты.

Казан шәһәрендә системалы рәвештә физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүче кешеләр санын арттырырга ярдәм итә торган «Хезмәткә һәм оборонага әзер» бөтенроссия физкультура-спорт комплексы проектын (алга таба – «Хезмәткә һәм оборонага әзер» проекты) гамәлгә ашыру дәвам итә.

2025 елда «Хезмәткә һәм оборонага әзер» проекты сынауларын үтүдә һәм аның күрсәтмә чараларында 61 меңнән артык кеше катнашты.

## Шәһәр халкы сәламәтлеген саклау

Казан шәһәре халкына медицина ярдәме күрсәтүнең сыйфаты мәсьәләсе депутатлар тарафыннан аерым контрольдә тотыла.

Югары технологияле медицина ярдәме өлкәсендә заманча мөмкинлекләрне өйрәнү максатыннан Казан шәһәре Думасы депутатлары Төбәкара клиника-диагностика үзәгендә булдылар.

Алар медицина учреждениесенең төп объектлары белән таныштылар һәм түбәндәге бүлекләрне карадылар:

- 11 операция залы булган операция блогы;
- кан әзерләү һәм йөрәк-кан тамырлары авыруларыннан интегүче пациентларга ашыгыч ярдәм күрсәтү бүлекләре;
- хәрәкәтне анализлау лабораториясе;
- нур диагностикасы бүлеге;
- ультратавыш диагностикасы кабинеты.

Төбәкара клиника-диагностика үзәгенең кураторлык эше тәҗрибәсе Татарстанда кан тамырлары авыруларын дәвалау белән шөгыльләнүче 18 үзәк эшчәнлеген координацияләргә ярдәм итә. Депутатлар, югары технологияле операцияләрне һәм диагностиканың заманча ысулларын да кертеп, йөрәк-кан тамырлары һәм неврология авыруларыннан интегүче пациентларга ярдәм күрсәтүгә комплекслы якын килү алымнары белән таныштылар.

Алар сәламәтлек саклау системасын яхшырту өчен шәһәр хакимияте һәм медицина бергәлеге арасындагы хезмәттәшлекне ныгыту буенча эшне дәвам итү мөһимлеген билгеләп үттеләр.

## Законлылык, хокук тәртибе һәм җирле үзидарә мәсьәләләре

Шәһәр Думасы алдында торган бурычларның чираттагысы – норматив-хокукый база булдыру. Әлеге максаттан депутатлар тарафыннан күп кенә карарлар кабул ителде. Узган елда законлылык, хокук тәртибе мәсьәләләре һәм җирле үзидарә буенча даими комиссия утырышларында 85 тән артык материал карап тикшерелде.

Депутатлар тарафыннан каралган мәсьәләләрнең кайберләре: «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында», «Территориаль иҗтимагый үзидарәләрнең чикләрен билгеләү турында», «Муниципаль контроль турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында», «Муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда планнан тыш тикшерүләр үткәрү зарурлыгын билгеләү өчен кулланыла торган мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары исемлеген раслау турында», «Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре турында» һәм шәһәрнең тормыш эшчәнлеген тәэмин итүгә юнәлдерелгән башка мәсьәләләр.

Шәһәрдә һәм транспорт объектларында – җәмәгать тәртибен, шулай ук башкалада юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү мәсьәләләре элеккечә депутатларның игътибар үзәгендә.

2025 елда депутатлар Россия Эчке эшләр министрлыгының транспортта Казан линия идарәсе вәкилләре катнашында утырыш үткәрде. Депутатлар билгеләп үткәнчә, хокук саклау органнары тарафыннан казанлыларның имин яшәешен тәэмин итү һәм башкалада эре халыкара чаралар уздыру барышында, шулай ук һава, су һәм тимер юл транспорты объектларында шәһәр халкының һәм кунакларының куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча барлык тиешле чаралар күрелә.

Депутатлар инициативасы белән гражданнар оборонасының саклану корылмаларына, тирәнлектә ясалган һәм җир астындагы башка корылмаларга (торак йорт подваллары, җир асты кичүләре, метрополитен станцияләре) инвентаризация үткәрелде. Ул ел саен уздырыла. 2025 елда барлыгы 308 сыену урыны һәм күпфатирлы торак йортларда 6012 подвал, 35 паркинг һәм тирәнлектә ясалган башка корылмалар (балалар бакчаларындагы, мәктәпләрдәге, сәүдә үзәкләрендәге, дәвалау учреждениеләрендәге, икътисад объектларындагы подвал бүлмәләре һ.б.) тикшерелде. Күпфатирлы торак йортларда саклану корылмалары буларак җайлаштырылган подваллар ишекләренә юнәлешне күрсәтүче уклар (2186 данә) һәм элмә такталар (2572 данә) урнаштырылды.

## Сайлаучылар һәм халык белән эшләү, Шәһәр Думасы эшендә хәбәрдарлыкны тәэмин итү

Казан шәһәре Думасы депутатлары халыкны үз округларында һәм сәяси партияләрнең җәмәгатьчелекне кабул итү бүлмәләрендә кабул итә.

Сайлаучыларны кабул итү графигы, кабул итүне үткәрү датасын һәм урынын күрсәтеп, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында урнаштырыла.

Казан шәһәре Думасы депутатлары тарафыннан 2025 елда уздырылган кабул итүләр саны – 1,1 меңнән артык.

Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының kzn.ru рәсми порталы аша депутатларга мөрәҗәгать итү мөмкинлеген тәэмин итә торган «Депутатка мөрәҗәгать итү» сервисы үз эшен дәвам итте. Ул гражданнар өчен депутатлар корпусыннан җавап алу процессын сизелерлек гадиләштерде. Әлеге сервис аша барлыгы 6425 мөрәҗәгать керде, аларның барысы да хәл ителде.

Хисап чорында Шәһәр Думасы эшчәнлеге сайлаучылар һәм шәһәр җәмәгатьчелеге өчен ачык булды, хәбәрдарлык принципларына нигезләнде, шулай ук башкарма хакимият белән тыгыз хезмәттәшлектә алып барылды.

Казан шәһәре Думасы регламенты һәм муниципаль хокукый актлар нигезендә барлык карарлар «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарылды һәм Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) урнаштырылды.

## Хәйрия эшчәнлеге һәм иҗтимагый эшчәнлек

Мобилизацияләнүчеләргә һәм аларның гаиләләренә ярдәм итү буенча масштаблы эш 2025 елда да алып барылды. Һәр гаилә белән элемтә урнаштырылды, конкрет ярдәм чаралары эшләнде.

«Игелекле Казан» коммерциягә нигезләнмәгән автоном оешмасы бердәм тәрәзә функциясен үтәвен дәвам итте. Ул 134 фондны һәм инициативаны берләштерә. Ел дәвамында шәһәрнең коммерциягә нигезләнмәгән оешмаларына ресурс, грант ярдәме, чаралар үткәрүдә, муниципаль һәм коммуналь хезмәтләр белән бәйле мәсьәләләрне хәл итүдә ярдәм күрсәтелде.

Сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле һәм авыр тормыш хәлендә калган кешеләр өчен төрле проектларны гамәлгә ашыру «Игелекле Казан» коммерциягә нигезләнмәгән автоном оешмасы эшчәнлегенең өстенлекле

юнәлеше булып кала бирә. Узган елда барлыгы 4 570 тән артык кешегә хезмәт күрсәтелде.

2025 елда «Игелекле Казан» коммерциягә нигезләнмәгән автоном оешмасы катнашында түбәндәге проектлар гамәлгә ашырылды:

- авыр тормыш хәлендә калган кешеләр өчен кайнар линия (50 000 нән артык шалтырату кабул ителде);

- инвалид балалар арасында спортны үстерүгә юнәлдерелгән «Игелекле спорт» проекты. Ел дәвамында чаңгы, җиңел атлетика, йөзү, йөгерү, велосипедта йөрү буенча ярышлар уздырылды, хәйрия шугалаклары һәм башка чаралар оештырылды;

- «Социаль такси» проекты кысаларында 1 200 кешегә ярдәм күрсәтелде, «Игелекле автобус» проекты кысаларында исә 72 мәртәбә истәлекле урыннарга, шул исәптән Татарстан Республикасының һәм якын төбәкләрнең тарихи урыннарына сәяхәт кылынды;

- инвалидлыгы булган кешеләрне социальләштерү һәм эшкә урнаштыру (инвалидлыгы булган һәм сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле 100 дән артык яшь кеше эшкә урнаштырылды, 37 кеше социальләшү уза);

- инвалидлык статусын алмаган, әмма тернәкләндерү чараларына ихтыяҗы булган кешеләргә ярдәм күрсәтүгә юнәлдерелгән «Сәламәтлек» проекты (483 кешегә ярдәм күрсәтелде);

- инклюзив волонтерларны укыту. Бүгенге көндә «Игелекле Казан» волонтерлык хәрәкәтендә 800 дән артык кеше исәпләнә, аларның иң кечкенәсенә – 7, ә иң өлкәненә – 87 яшь;

- менталь тайпылышлары булган балалар өчен көндезге лагерь сменалары (600 бала өчен 30 дан артык смена оештырылды);

- сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле балалар өчен «Облачко» футбол командасы (финанс һәм оештыру ярдәме);

- шәһәрнең инклюзив остаханәләре продукциясен сату буенча «Игелекле сувенир» сәүдә нокталары (сатылган продукциянең гомуми суммасы – 2 млн сумнан артык);

- Калинин урамы, 3 йорт адресы буенча ачылган складта кием-салым җыю, аларны мохтаҗларга тапшыру;

- Серов урамында урнашкан инклюзия юнәлешендәге бульварда балалар церебраль параличы диагнозы куелган авырулар өчен велосипедларны прокатка бирү һ.б.

«Игелекле Казан» коммерциягә нигезләнмәгән автоном оешмасы тарафыннан шәһәр районнарында сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле

балалар өчен инклюзив ял итү үзәкләре һәм менталь тайпылышлары булган балалар өчен уку-укыту һәм күнекмәләр фатирлары оештырыла. Бүген Казанда шундый өч учреждение бар: «Луч» уку-укыту һәм күнекмәләр фатиры, «Тылсым» күпфункцияле үзәге, «Крылья» мультиформатлы үзәге.

«Вместе» балалар инклюзив үзәген ачу 2025 елның мөһим вакыйгасы булды. Проект Казан шәһәре Башкарма комитетының Совет районы администрациясе, битараф булмаган эшмәкәрләр, Казан шәһәре Думасы депутатлары һәм Президент грантлары фонды ярдәме белән гамәлгә ашырылды. Үзәк август аенда ачылды һәм бик тиз арада популярлык казанды: хәзер анда сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле һәм инвалидлыгы булган, шулай ук статистик психик нормага туры килә торган 300 дән артык бала йөри.

Мондый ачык киңлекләр ел саен барлыгы 4 000 нән артык үзенчәлекле баланы колачлый.

Шулай ук 2025 елда менталь тайпылышлары булган кешеләр өчен «БлагоДарю» коммерциягә нигезләнмәгән автоном оешмасы социаль адаптация үзәгенең икенче фатиры ачылды. Анда өч егет яши, һәрберсенең үз бүлмәсе бар. Алар уртак көнкүреш алып баралар, эшлиләр. Проектның төп бурычы – менталь тайпылышлары булган кешеләргә интернатлардан читтә гадәти көндәлек тормыш белән яшәргә мөмкинлек тудыру.

Язгы һәм көзге чорларда игелек ярминкәләре үткәрелде. Акция кысаларында 2025 елда 15 млн сумнан артык акча җыелды. Акчалар хәйрия фондларына, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучы хәрби хезмәткәрләргә һәм аларның гаиләләренә ярдәм күрсәтү өчен тотылды.

«Игелекле Казан» проектлары грант һәм иганә акчаларына гамәлгә ашырыла. 2025 елда җәлеп ителгән грантлар – 27 млн сумнан, иганә акчалары күләме 50 млн сумнан артты.

Махсус хәрби операциядә катнашучы хәрбиләрнең гаиләләре 2025 елда да төрле ташламалардан файдалана алды.

Шәһәр пассажир транспортында бушлай йөрү өчен хәрби хезмәткәрләрнең 8 яшьтән 18 яшькә кадәрге балаларына ташламалы юл билетлары (транспорт карталары) бирү эше дәвам итте. Барлыгы 6258 карта бирелде, алар буенча 1 989 097 мәртәбә юлда йөрү гамәлгә ашырылган.

Мәктәптә хәрби хезмәткәрләрнең балалары ике тапкыр бушлай ризык белән тәэмин ителә. 2025 елда 5140 укучы бушлай тукланды.

Шулай ук хәрби хезмәткәрләрнең балалары мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә абонент түләвеннән һәм тукланган өчен түләүдән азат ителде. Абонент түләвеннән азат ителүчеләр саны – 2116 бала.

Моннан тыш, хәрби хезмәткәрләрнең 18 яшькә кадәрге балаларына Казан шәһәренең дәүләт һәм муниципаль мәдәният учреждениеләрендә уза торган чараларга «Батыр» махсус пластик картасы белән бушлай керү мөмкинлеге булдырылды. Барлыгы 8876 карта тапшырылды. Шәһәрнең 45 мәдәният учреждениесе тарафыннан 107 меңнән артык ташламалы билет бирелде.

Хәрби хезмәткәрләрнең балаларына 30 спорт учреждениесендә 40 тан артык хезмәт бушлай күрсәтелә, шул исәптән алар билгеләнгән вакытта җиңел атлетика манежларына, бассейннарга, тренажер залларына һ.б. йөри ала.

«Яшүсмер» муниципаль бюджет учреждениесе тарафыннан махсус хәрби операциядә катнашучыларның балаларын түгәрәкләргә һәм секцияләргә өстәмә җыю оештырылды.

Мобилизация башланганнан бирле «Доверие» үзәгенә, психологик ярдәм сорап, 927 кеше мөрәҗәгать итте. Күңел төшенкелеге кичергән 387 кешегә ашыгыч рәвештә психолог ярдәме күрсәтелде.

«Доверие» үзәгенең Вахитов районында (М.Сәлимҗанов урамы, 14 йорт) урнашкан психологик хезмәте базасында мобилизацияләнгән затларның хатыннары һәм әниләре өчен төрле ярдәм төркемнәре оештырыла. Бирелә алар үз фикерләрен әйтә һәм хисләре белән уртаклаша, шулай ук психологлар һәм төркемдә катнашучы башка хатын-кызлар ярдәменә өметләнә ала.

Казан шәһәрендә шулай ук 16 медицина-психологик консультация кабинеты һәм 12 психотерапия кабинеты эшли.

«Игелекле Казан» кайнар линиясе – махсус хәрби операциядә катнашучыларның туганнарына, катлаулы тормыш хәлендә калган кешеләргә консультация һәм ярдәм күрсәтүче гомумшәһәр телефоны үз эшен дәвам итте.

2025 елда 50 144 шалтырату кабул ителде. Шул ук чорда кайнар линия аша алынган мөрәҗәгатьләр нигезендә түбәндәге ярдәм чаралары күрсәтелде:

- 2751 гаилә 3 306 702 сумлык азык-төлек һәм көнкүреш химиясе җыелмалары алды;

- 376 гаиләгә коммуналь хезмәтләр өчен түләүдә һәм торак арендалауда, ремонт эшендә, көнкүреш техникасы сатып алуда һәм башка мәсьәләләрдә 6 963 128 сумлык ярдәм күрсәтелде;

- 803 гаиләгә балалар ризыгы һәм подгузниклар сатып алуда 4 239 840 сумлык ярдәм күрсәтелде;

- 484 гаиләгә дару сатып алуда һәм медицина хезмәтләреннән файдалануда 2 589 400 сумлык ярдәм күрсәтелде;

- гаилә әгъзалары «хәбәрсез югалган» статусында булган 77 гаилә 1 925 000 сумлык матди компенсация алды.

Шулай ук гаиләләргә волонтерлар тарафыннан даими рәвештә ярдәм күрсәтелә (азык-төлек, дарулар сатып алу, утын бушату, йорт янындагы участокларны тәртипкә китерү, үлән чабу, кар чистарту, техника ремонтлау, вак-төяк ремонт һ.б.).

Хәрби хезмәткәрләрнең гаиләләре Казан шәһәренең медицина хезмәте тарафыннан патронажга алынды, аларны медицина хезмәте белән тәэмин итү мәсьәләсе өстенлекле тәртиптә хәл ителә.

## 2026 елга бурычлар һәм эшчәнлекнең төп юнәлешләре

1. Бюджет үтәлешен һәм бюджет акчаларыннан файдалануны контрольдә тоту.
2. 2030 елга кадәр Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең социаль-икътисади үсеш стратегиясен гамәлгә ашыру.
3. 2030 елга кадәр (перспективада 2040 елга кадәр) Казанның тотрыклы үсеш стратегиясен гамәлгә ашыру.
4. 2025 елның 17 октябрендәге 863 номерлы «2026 елны Татарстан Республикасында Хәрби батырлык һәм хезмәт фидакарьлеге елы дип игълан итү турында»гы Татарстан Республикасы Рәисе Указы кысаларында чараларны гамәлгә ашыру.
5. Казан шәһәрендә сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле кешеләрнең тормыш сыйфатын яхшырту өчен шартлар тудыру.
6. Шәһәрнең экологик иминлеген арттыру, калдыклар белән эш итүнең яңа стандартларын гамәлгә кертү.
7. Шәһәр ишегалларын төзекләндерү һәм яңа җәмәгать урыннарын (парклар, скверлар, яр буйлары) булдыру.
8. Шәһәрлеләрнең тормыш дәрәҗәсен күтәрү һәм керемнәрен арттыру, яңа эш урыннары булдыру һәм соры хезмәт базары белән көрәшү.
9. Шәһәр хуҗалыгының барлык өлкәләрендә заманча цифрлы технологияләрне гамәлгә кертү.
10. Белем бирү дәрәҗәсен күтәрү өчен шартлар тудыру, шул исәптән мәгариф учреждениеләре төзү һәм аларны капиталь ремонтлау.
11. Гражданнарны мәдәният, яшьләр сәясәте учреждениеләре хезмәтләре белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру.
12. Төрле өлкәләрдә муниципаль контрольне (торак, җир контролен, капиталь ремонт, төзекләндерү өлкәләрендә һ.б. контрольне) гамәлгә ашыру.

13. Шәһәр дәваханәләрендә, идарәче компанияләрдә халыкка хезмәт күрсәтү сыйфатын контрольдә тотуны гамәлгә ашыру.

14. Шәһәр халкы мәнфәгатьләрен яклау һәм халыкка социаль ярдәм күрсәтү чараларын саклап калу.

**Башлыкның беренче урынбасары** **Д.Г.Калинкин**